ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» августыннан № ____

Мәктәп автобуслары маршрутларын раслау турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының база гомуми белем бирү учреждениеләренә укучыларны имин һәм өзлексез йөртүне тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемен автобуслар белән оешкан рәвештә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 сентябрендәге 1527 номерлы карары нигезендә, шулай ук мәгариф оешмалары тарафыннан транспорттан файдалану мөмкинлеген һәм укучыларны йөртү куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 сентябреннән түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:

1 номерлы маршрут: Екатерина Бистәсе ав. – Чуаш Чабаксары ав. - Рус Чабаксары ав. – Екатерина Бистәсе ав. – Яңа Иванаево ав. – Екатерина Бистәсе ав. «Екатериновка төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Х204НХ д/н автобус, «Екатериновка төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

2 номерлы маршрут: Ленино ав. – Акъяр ав. – Горшково ав. – Ленино ав. – Тубылгы Тау ав. – Ленино ав. «Ленино урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Т 185 НХ д/н автобус, «Ленино урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

3 номерлы маршрут: Чаллы Башы ав. – Шахмай ав. – Чертуш ав. – Шахмай ав. – Акъяр ав. – Шахмай ав. – Чаллы Башы ав. «Шахмай урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (ВТ 330 16 д/н автобус, «Шахмай урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

4 номерлы маршрут: Яңа Чишмә ав., Яр буе урамы, 2 йорт – Архангел Бистәсе ав. – Яңа Чишмә ав. Гряда урамы – Яңа Чишмә ав., Көнбатыш микрорайоны – Яр буе урамы 2 йорт «Яңа Чишмә урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Х 920 РЕ д/н автобус, «Яңа

Чишмә урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

5 номерлы маршрут: Зирекле ав. – Архангел Бистәсе ав. – Әдәмсә ав. - Ленино ав. – Тубылгы Тау ав. – Әдәмсә ав. – Зирекле ав. - Өргәнче ав. – Зирекле ав. «Зирекле лицее» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (АС 743 16 д/н автобус, «Зирекле лицее» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

6 номерлы маршрут: Петропавел Бистәсе ав. – Андреевка ав. – Екатериновка ав. – Яңа Чишмә ав. «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (ВТ 331 16 д/н автобус, «Петропавловка төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

7 номерлы маршрут: Акбүре ав. – Волчья Бистәсе ав. – Акбүре ав. «Акбүре төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (АС 744 16 д/н автобус, «Акбүре төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

8 номерлы маршрут: Яңа Чишмә ав. – Чуаш Чабаксары ав. – Екатерина Бистәсе ав. – Яңа Иванаево ав. – Яңа Чишмә ав. «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе – СОМ заводы – Көнбатыш микрорайоны – Яңа Чишмә ав. «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Т 486 ВС д/н автобус, «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе);

9 номерлы маршрут: Яңа Чишмә ав. – Акбүре ав. – Волчья Бистәсе ав. – «Красный Октябрь» совхозы посёлогы– Яңа Чишмә ав. «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе - СОМ заводы – Көнбатыш микрорайоны – Яңа Чишмә авылы «Яңа Чишмә башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Х 739 РЕ д/н автобус, «Яңа Чишмә гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе).

2. «Алексеевскдорстрой» ААҖ генераль директорына мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутларында автомобиль юлларын, тукталыш пунктларын һәм борылыш мәйданчыкларын юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә җавап бирә торган хәлдә карап тотуны тәэмин итәргә, шулай ук кышкы чорда юлларны кардан һәм боздан чистарту чараларын, шулай ук маршрутларның өзлексез һәм имин эшләве өчен кирәкле башка чараларны үз вакытында үткәрергә тәкъдим итәргә.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсе башлыгына расланган мәктәп автобус маршрутлары буенча укучыларны йөрткәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы рәисенә балаларны мәктәп автобуслары белән йөртү өчен кирәкле акча бүлеп бирергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Рөстәм улы Камалетдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов